# Татар авылы:
# Үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге

*/ Бөтендөнья татар конгрессының “Татар авыллары ассоциациясе” төзү Җыенында ясаган чыгыш./*

Бүгенге көндә дөньядагы татар авылларының төгәл санын беркем дә әйтә алмас, чөнки алар хисапка алынмаган, тарихлары махсус өйрәнелмәгән, бүгенге хәлләре күпләргә билгесез. Тын океаннан Урал тауларына хәтле, ягъни, Новосибирски, Иркутски, Красноярски, Омски, Томски, Төмән, Курган, Чиләбе өлкәләрендә меңгә якын татар авылы булырга тиеш, Ырынбур, Свердловски, Пермь өлкәләре һәм Башкортстанда тагы шуның хәтле, Татарстан, Удмуртия, Мари-Эль, Чувашия, Мордовиядә, Киров өлкәсендә һәм мишәр якларында – Түбән Новгород, Пенза, Саратов тирәләрендә, Әстерхән һәм Ставрополь өлкәсендә җәмгысе меңнән артык татар авылы барлыгы билгеле. Бу – искиткеч зур байлык, гасырлардан калган зур мирас һәм тиңсез хәзинә, бу авылларда татар тарихы, ислам дине, милли мәдәният һәм матур гореф-гадәтләр, милли холык һәм татарның асыл сыйфатлары сакланып калган. Әмма алар, иксез-чиксез кыпчак даласындагы ком бөртекләре кебек, Татар Иле буйлап таралып яталар, кайсылары гөрләп чәчәк ата, кайсылары бетеп ята, кайсылары турында белүче дә юк.

Бу татар авыллары арасында Пенза өлкәсендәге Урта Әләзән кебек, ун мең кешелек гайрәтле, өметле мөселман авыллары да, Омски өлкәсенең Кумыслы авылы кебек, бер йортка калып, таралып беткәннәре дә, Чиләбе өлкәсенең Татар Караболагы кебек, 50 ел буе атом радиациясе астында яшәргә мәҗбүр булганнары да, Ставрополь краенын Кече Барханчык авылы кебек, как далада берьялгызы утырганнары да, Төркиянең Бөгередәлек себер татарлары авылы кебек, йөз ел буе туган илсез яшәүчеләре дә бар... Әмма алар барысы да – татар авыллары, һәм алар турында кайгырту – Бөтендөнья татар конгрессының төп эше, дип уйлыйм. Югыйсә без моңа кадәр гел шәһәр татарлары белән мавыктык, оешмалар анда төзелде, Казаннан ярдәм аларга килде, ә авыл татарлары гел бер читтә торып калды. Ниһаять, татар конгрессы төп нигезгә – Татар Авылына йөз белән борылды, бүгенге җыелыш әнә шул турыда сөйли.

Әйе, һәр татар авылына төшеп җитми торып, без милләтне уята алмаячакбыз. Бүгенге шәһәр халкының да тамырлары авылда, менталитеты авылча, димәк, авылны аңламый һәм аңа ярдәм итми торып, без татар тормышын да тулысынча аңлый алмаячакбыз, халыкны милли бәйсезлек өчен көрәшкә күтәрә алмаячакбыз. Әлбәттә, бөтен дөнья буйлап таралып яткан меңләгән татар авылы белән эшләү шактый авыр булачак, әмма ул эшне башлар вакыт җитте. Һәм бу эшне системага салып, планлы рәвештә, даими һәм дәвамлы алып барырга кирәк. Югарыда санап киткән өлкәләрдәге татар авылларының күпчелегендә булган һәм шушы теманы даими рәвештә матбугатта яктыртып торган кеше буларак, бүгенге олы җыенга минем кайбер тәкъдимнәрем дә бар.

Иң беренче эш итеп, урыннардагы җирле оешмаларның ярдәме белән безгә һәр төбәктәге татар авылларының тулы исемлеген булдырырга кирәк. Компьютерда мәгълүматлар базасын булдырганнан соң, эш ике төп юнәлештә китәргә тиеш, дип уйлыйм. Беренчесе – Казан галимнәре һәм җирле милли зыялылар ярдәмендә, ул авылларның тарихын өйрәнә башлау һәм һәр төбәкнең татар авыллары турында китап-брошюралар бастырып чыгару. Башкортлар бу эшне инде күптән башкарып чыктылар,

әмма татар исәбенә башкардылар, безгә ул ялгышны төзәтеп, үз тарихыбызыны язарга кирәк. Алдагы биш елда җирле татар оешмаларының, милли матбугатның төп эше шушы булырга тиеш, дип уйлыйм, һәм алдагы конгресс составына да шушы эшне эшләрдәй кешеләрне генә кертергә кирәк. Әмма урыс архивларына таянып кына төбәктәге татар авылларының тарихын 17-18 гасырларга гына кайтарып калу зур ялгыш булачак, заманында Болгар дәүләте, Төрки каганатлар, Алтын Урда, Себер, Казан, Әстерхан, Касыйм ханлыклары җирләрендә урнашкан татар авыллары шушы татар дәүләтләренең яше белән билгеләнергә тиеш. Һәм бу татарлар ул җирләрдә диаспора булмыйча, төп җирле халык икәнлеген һәр адымда искә төшереп торырга кирәк.

Икенче юнәлештәге эш – татар авылларының бүгенге социаль хәлләрен өйрәнү, кайда мәктәп, кайда мәчет, кайда мәдәният учаклары булу-булмавын ачыклау, халыкка шул мәсьәләләрдә ярдәм итү. Сүз монда матди ярдәм итү турында гына бармый, бу авыллар күп очракта хокукый ярдәмгә мохтаҗ булалар, рухи ярдәмгә тилмереп яталар, гомерләрендә бер татар язучысы, бер татар артисты күрмичә яшиләр. Аларга безнең китапларыбыз, иманлы сүзебез, милли кадрларыбыз кирәк. Казан, Бөтендөнья татар конгрессы һәр татар авылындагы социаль хәлне биш бармагы кебек белергә һәм кирәк вакытта ярдәмен күрсәтергә тиеш, дип уйлыйм.

Татар конгрессы һәм татар авыллары арасында даими һәм ныклы элемтә булсын өчен, зуррак авыллардан булса да турыдан-туры Казан белән эшләрлек кешеләрне табарга кирәк. Алар бар, әмма Казан моңа кадәр шәһәр милли оешмалары белән генә эшләгәнлектән, авыллардагы бу актив кешеләр гел читтә кала бирде. Безгә бу авыл элитасы белән махсус эшләргә кирәк булачак, һәм алдагы этапта аларның бер киңәшмәләрен җыеп алсак та яхшы булыр иде. Әмма без өлкә номенклатурасы әзерләп биргән түрә-татарлар белән генә эш йөртсәк, әллә ни алга китә алмабыз, чөнки мондыйлар гадәттә милләткә түгел, югарыдагыларга хезмәт итә. Ягъни, безгә авылларда кәгазь татарлар түгел, милләт өчен янып йөргән, эш күрсәтерлек лидер татарлар кирәк, алар, сирәк булса да, бар әле...

Һәм бу авылларга без нинди идеология салырга телибез, аларны кая, кай тарафка таба өндибез – монысы да бүгеннән үк билгеле булырга тиеш. Бу татар авылларын “Единая Россия” яки тагы шундый берәр шовинистик Россия партиясенә тавыш бирдерү өчен генә барлыйбыз һәм берләштерәбез икән, мондый эшнең булганнан булмаганы яхшы. Кызганычка каршы, без Россия буенча үзебезнең татар партиясен төзеп куя алмадык, ә башка партияләр барысы да татарга каршы эшли, шулай булгач, татарларның бу сайлауларда катнашулары хич кирәк түгел. Ул чагында бәлки безнең белән хисаплашырлар иде.

Татар халкы кайда гына яшәсә дә, үзенеә дәүләтчелеген булдырырга омтылырга, иманлы татар булып сакланып калу өчен көрәшергә тиешле. Бүген милләтнең дә, татар авылларының иң йомшак урыны – менә шушы милли идеологиянең булмавы, халыкның вак максатлар белән ваклануы һәм кыйбласыз калуы, иң куркыныч ягы – әхлаксызлык. Татар авылларына яңадан ислам әхлагын кире кайтарганда гына без милләтебезне саклап кала алырбыз, татар җиренә тамыр җибәреп яткан эчкечелек, наркомания, фахишәлек, җинаятьчелек кебек яман күренешләрдән котылырбыз. Моны халыкка һәр көн аңлатып торырга, үзебезгә дә исламча яшәү үрнәген күрсәтергә кирәк булачак.

Халык яңадан дәүләтле булырга, үз ана телебездә сөйләшергә омтылсын өчен, милли үзаң өстендә нык эшләргә кирәк. Югыйсә, бүгенгесе көндә Татарстан һәм Башкортстаннан тыш татар авылларында өч буын урысча укыган нәселләр барлыкка килде, алар татар телен дә, татар тарихын да белмиләр, милләт белән горурланмыйлар, үз туган җирләрендә мескен манкортка әйләнеп баралар. Югыйсә бездә меңәр еллык зур тарихы булган татар авыллары, халкыбызга бөек шәхесләрне биргән төбәкләр бар

бит! Казан белән бергәләп менә шундый авылларың юбилейларын уздыру, алар турында махсус китаплар чыгару, тапшырулар эшләү милләтнең үзаңын уятырга ярдәм итәр иде. Бу нисбәттән “Татарстан – Яңа гасыр” каналы күп эш эшли ала, әмма аның атнага бер тапкыр булган авыл программасы урып-җыюга һәм ферма эшләрен яктыртуга гына кайтып кала, ә татар авылларының тарихы, рухи мирасы, милли проблемалары, милләт өчен янып йөргән кешеләре аларга кирәк түгел.

Татар авыллары милләтебезгә бик күп талантлар бирде, мондый авылларны аеруча хисапка алырга һәм игътибар үзәгендә тотарга кирәк, дип уйлыйм. Әйтик, заманында Пенза өлкәсендә танылган драматург Кәрим Тинчурин туган Тархан авылы бүген Таракановка дип йөртелә, анда татар мәктәбе юк, татарча укый-яза алучы бер генә татар баласы да юк, Кәрим Тинчуринга истәлек тактасы юк. Безне Тархан милләттән тараканга әйләндерүчеләр бу хәлдән канәгатьтер, әмма ник без үзебез моның белән ризалашабыз?! Пенза өлкәсендә шулай ук Шамил Усманов туган Татар Пәндәлгәсе, Муса Бигиев туган Кикин авылларында да ни истәлек такталары, ни музейлар юк, бу шәхесләрнең бер китаплары юк, бары тик Гадел Кутуй туган Татар Кынадысы авылында гына язучыга мәктәпнең бер бүлмәсендә музей ачканнар. Шулай ук Пенза өлкәсенең күршесе булган Мордовия республикасында Габдрахман Әпсәләмов туган Иске Аллагол авылында, Гафур Колахметов җирләнгән Татар Юнәсе авылында да шушы ук хәл, бары тик Һади Такташ туган Сыркыды авылында гына Татарстанның сәламәтлек министры Камил әфһәнде Зыятдинов ярдәмендә шагыйрьгә музей салып куйдылар. Милләтнең бөекләре туган төбәкләргә карата игътибарсызлыкны, кадерсезлекне бөтен дөнья буйлап күреп, җан әрни, безне дә шушы көн көтә икән, дип уйлыйсың... Урыннардагы җирле оешмалар һәм Казан мондый авылларга аеруча игътибарлы булырга, аларны күз алдында тотарга, даими ярдәм күрсәтеп торырга тиешләр.

Бүгенге татар авыллары рухи яктан гына түгел, социаль яктан да бик зур проблемалар алдында калдылар, бу бигрәк тә Урал аръягында ачык күренә. Бу якларда күпчелек татар авылларында бернинди хакимият юк, җирле үзидарәләр урыс авылларына күчерелгән, татар авыллары газсыз, юлсыз интегә, халыкка хезмәт хакы алырлык эш юк. Җитмәсә, Себер авылларына кытайлар күз салган, подставной кешеләр аша алар бу җирләрне сатып алалар, юк кына бәягә анда татарларны эшләтәләр, рус хатыннарына өйләнеп, шунда хуҗа булып калалар. Алга таба Себердә һәм Урал буйларында кытай проблемасы бик җитди торачак, татар авылларына да шулар хуҗа булып калырга мөмкин, әмма бу хакта Казанда бер генә милли оешма да уйламый әле. Тарихны аз-маз белгән һәм милли горурлыгы булган татар беркайчан да җирен кытай кешесенә сатмас иде, чөнки элек-электән туган җиреңне сату ул илеңне сату белән бер булган, бу очракта мин ил, дигәндә, шушы татар авыллары урнашкан Татар Илен күздә тотам. Безнең бүген җирләребез бары тик шушы татар авылларында гына, ә шәһәр татарының туган җире дә, туган иле дә юк аның...

Әйе, бүгенге татар авыллары күп төрле, аларның проблемалары да төрле. Кемнәрдер табигый газга һәм яхшы юлларга тилмерсә, кемнәргәдер инде спутник тәлинкәсе, интернет, дөнья белән аралашу чаралары кирәк. Әмма күпчелек татар авыллары бер проблемадан интегә – эшсезлек һәм акчасызлык. Колхозлар бетте, фермерлар эшләп китә алмады, инвесторлар да күпчелек очракта халык турында уйламый, байлык турында уйлый. Авыллар үз-үзләренә эш оештыра алмыйлар икән, хәерчелектән башлары чыкмаячак. Мин оешуның матур үрнәген Төркиядә, себер татарлары авылы Бүгередәлектә күрдем – һәркемнең үз иген кыры бар, шул уңышны сатарга авылның үз кооперативлары бар, шәхси тегермәннзре эшләп тора, шәһәрләрдә кибетләре, рестораннары бар. Анда бер татар да мескен түгел, чөнки җирдә утырып, мескен булырыга ярамый! Алар йөз ел элек күчеп киткән Себер авылы Яланкүлдә мин шул

хәтле мескенлекне һәм фәкыйрьлекне күреп, тетрәндем, анда юл да юк, газ да юк, эш тә юк, акча да юк... Безнең татар авылларына да шәхси иген кырлары, фермалар, тегермәннәр, авыл хуҗалыгы продуктларын эшкәртергә шәхси яки кооператив сөт, ит, яшелчә мини заводлары тотар вакыт җитте. Авыл заманча яшәргә һәм эшләргә өйрәнми икән, ул һәрвакыт кемгәдер кол булачак я бетәчәк. Бүгенге көндә дәүләттән ярдәм көтеп утыру ул –үлем көтеп утыру белән бер. Шуңа күрә бу шартларда авыл үз-үзен оештырырга өйрәнергә тиеш. Без, татар зыялылары, авыл халкының хезмәткә карата мөнәсәбәтен һәм психолгиясен үзгәртергә ярдәм итәргә тиешбез.

Әйткәнемчә, бүген күпчелек татар авылларында җирле хакимият юк, халык үз проблемалары белән берьялгызы калган. Дөрес, без октябрь революциясенә хәтле дә шулай яшәдек, патша хакимияте безнең проблемаларны хәл итмәде, җәза ролен генә үтәде. Ул чакта милләт һәр авылда мәхәлләләр булып оешты, ил агалары, аксакаллар, абызлар сүзен тыңлады, ислам казыйлары хөкеменә буйсынды, милли һәм дини тәртип буенча яшәде. Димәк, татар авылларына яңадан **мәхәллә** системасын кертү ул инде өлгергән мәсьәлә, котылгысыз нәрсә. Авылда мәчет бармы-юкмы, ул эшлиме-юкмы – боларга карамый, мәхәллә булырга тиеш, мәхәллә үз тирәсенә ил картларын, эш адәмнәрен, милли зыялыларны җыярга һәм авылдагы проблемаларны хәл итәргә тиеш. Әлбәттә, бу тиз генә эшләнә торган эш түгел, әмма авылларда милләт булып оешуның башка юлы юк. Дәүләте булмаган милләт шулай үз-үзен оештырып кына исән кала ала, әмма моның өчен аңа акыл ияләренең ярдәме кирәк булачак.

Мин кайбер тарихчыларның: “Егерме елдан татар авылы бетә”, дигән фикере белән килешә алмыйм. Татар авыллары иң авыр елларда да, җир ашап, үлән ашап исән калдылар, алар өстеннән бөтен революцияләр, сугышлар, репрессияләр, тиф һәм ачлык үтте, әмма татар авыллары исән калды. Дәүләтчелегебез җимерелгәч, татар калалары юк ителгәч, милләт татар авылларына ышыкланып һәм укмашып исән калды, биредә ул үзенең тарихын язды, динне тотты, телне һәм мәдәниятне саклап калды. Бүгенге көндә дөньяда бер генә татар шәһәре дә юк, ә татар авыллары меңләгән... Һәм иң авыр вакытларда милләт тагы авыл каршына барып тез чүгәчәк, аңа сыеначак, анда сакланып калачак әле! Шуңа күрә, авылларын саклау – ул милләтне саклау, үзебезне саклау булачак. Бу җыенны мин милләтне саклап калу юлларын эзләүдә олы бер адым, дип исәплим, авыллар буенча яңа төзеләчәк оешмага уңышлар телим, бу изге эштә ярдәм итәргә теләгемне белдерәм.

**Фәүзия Бәйрәмова,**
***язучы, тарих фәннәре кандидаты,***
***Бөтендөнья татар конгрессының башкарма комитеты әгъзасы.***
2007 ел, 29 август.